


***Всероссийский конкурс для библиотек «Белая птица мира»***

***Кутлушкинская сельская библиотека – филиал №17***
***Муниципальное бюджетное учреждение культуры «Чистопольская межпоселенческая центральная библиотека» Чистопольского муниципального района.***

***Зарипова Ляля Минхадиевна***

# «Ил язмышын салып иңнәренә»


**Сугыш чоры балаларына багышлана**

*Сугыш ул- бик куркыныч нәрсә,*
*Кан ул, ут ул, үлем, яралар,*
*Күз яшьләре, ачлык, кайгы,*
*Тол аналар, ятим балалар.*

*Расул Гамзатов*

## *ТОРНАЛАР*

*Канлы яу кырларыннан кайтмый калган*
*Солдатлар кайчак килә уема,*
*Туфрак булмаган алар, ак торнага*
*Әверелгәндер кебек тоела.*
*Әлегәчә аларның шул заманнан*
*Килгән өненә колак салабыз.*
*Шуңа түгел микән без еш, моңаеп,*
*Күкләргә карап тынсыз калабыз?*
*Арыган кыйгач төркем сафы оча –*
*Кичке шәфәк нурына орынып.*
*Һәм шул сафта бер кечкенә ара бар, -*
*Бәлки, ул ара минем урындыр!*
*Килер дә бер көн – шул торналар белән*
*Чумармын мин дә күксел томанга,*
*Күк йөзеннән кош булып эндәшермен*
*Сезгә мин, җирдә калган туганнар.*
*Канлы яу кырларыннан кайтмый калган*
*Солдатлар кайчак килә уема,*
*Алар туфрак булмаган, ак торнага*
*Әверелгәндер кебек тоела.*



***Яүширмәдән  500 дән артык***
***ир-егет Ватанны сакларга китә.***







# *Ике героебыз белән горурланабыз*



***Советлар Союзы Герое Гали Шәмсетдинов 1917 нче елда Чистай районы Яуширмә авылында туа.***



***Советлар Союзы Герое Вәлиев Габделәхәт Габделганиевич***






## *Сибгатуллина Рәйсә Әһли кызы*







28 сентябрь 2000 ел. **Чистай хәбәрләре** 3

*1 октябрь – Өлкәннәр көне*

*Соңгы снарядлар, бомбалар шартлаган тавышлар инде бик еракта калды. Әмма халык күңеленә сугыш салган яралар әле дә булса онытылмый. Фоторәсемнән безгә хәрби киемнән саф күңелле, әле үсмерлегеннән аерылып та өлгермәгән яшь кыз карап тора. Без аны сугышчан дуслары белән бергә төшкән рәсеменнән алдык. Таныш булыгыз: ул 1925 елның декабрь аенда Яуширмә авылында туып үскән Рәйсә Әһли кызы Сибгатуллина була. Әлеге язмабыз аның турында булачак.*

### ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШ ИЯСЕ

Укырга, белем алырга атлыгып торган, шәфкать туташы булырга хыялланган кыз Чистайга фельдшер-акушерлар училищесына укырга килә. Аны тәмамлауга туган авылына зур өметләр белән фельдшер булып эшкә кайта. Зур дәрт, кызыксыну белән авыл халкына хезмәт күрсәтә башлый. Яшь кызга мәктәптән дә эш бирәләр. Гражданнар оборонасы дәресләрен алып бара ул. Эшнең җаена төшенеп, өч ай эшләүгә, сугыш башлана. Авылдан бер-бер артлы ир-егетләр сугышка китә башлый. Арада әнисенең бертуган энеләрен, аннан бертуган ике абыйсын да сугышка алалар. Рәйсәне дә сугышка алу мөмкинлеге турында сүз чыккач, әле сугышның мәкерле, коточкыч фаҗигасен аңлап бетермәгән кыз: «Мин алты малайга бер генә кыз, әти-әнием мине җибәрми, үзем дә китәргә тормыйм», — дип җавап бирә. Рәйсәне яратып йөргән егет Галиуллага да сугышка китәргә повестка китерәләр. «Сугыштан кайтканымны көтмәссең, кияүгә чыгарсың. Әйдә, вәгъдәләшик, көтәрсеңме мине, бергә булырбызмы», — ди егет кызга.

Халык тагын басу капкасына кадәр ир-егетләрне сугышка озата. «Вәгъдә — иман, Рәйсә» дип ал, зәңгәр төсләрдә чигелгән кульяулыгын егеткә тапшыра кыз. Шулай итеп, сөйгәннәреннән аерылып кайгы-моң, җыр белән сугышка китә егетләр.

Рәйсә апаны унҗиде яше тулып җиткәнне дә көтмичә сугышка алалар. Берданбер кызларының:

— Мин дә сугышка китәм, — дигән хәбәрен ишеткәч, әни кеше өнсез калып урын өстенә егыла. Әтисе пристаньга озатырга килгәч: «Китмә, кызым, кал инде, син бит авылга да бик кирәк кеше». — дип кызын калырга үгетли.

— Без күп булгач тизрәк җиңәрбез, әнә, тагын сугышка пароход тулы кеше китә, — дип әтисен тынычландырырга ашыга Рәйсә.

Шулвакыт яр буенда торган пароход сузып-сузып озын гудок бирә. Кызның күңелен аерылу хисе, сагыш-моң биләп ала. Ул әтисенең муенына килеп асылына һәм кычкырып елап җибәрә. Һай бу пароход тавышы, кызның йөрәген өзгәләп талый. Әтисеннән көчкә аерып алалар аны. Пароходка керүгә юлга кузгалалар. Аерылу газабын кыз бик авыр кичерә. Авырый башлый. Казан госпиталендә өч ай ятканнан соң гына сугышка китә Яуширмә авылыннан ку кырына киткән берданбер хатын-кыз була ул.

Беренче чыныгуны ул 1 нче Украина фронтында ала. Аннан 2 нче Белоруссия фронтына күчерелә.

— Баш очыбызда дошман туплары шартлап ярылган чаклар да булды. Ышыкланы урыны эзләп җиде кызыбыз дальномер астына кергәннәр. Бәр да бер мизгелдә һәлак булды. Тагын шуна охшаш фаҗига Белоруссиядә — типсә тимер өзәрдәй таза шәп алты сугышчан егет шулай берьюлы үлемгә дучар булды. Ике очракта да үлүчеләрнең гәүдәләрен эзләп, җыеп тормадылар. Аларның туган җи[...]ләренә «Хәбәрсез ю[...]ды» дигән телеграм[...]лар җибәрделәр. Һәм [...]уның белән вәссалам, бетте-китте, — дип әрнеп сөйли Рәйсә апа.


Ниһаять, сугыш бетә. 1945 елның июнь ахырында авылына кайта ул. Күкрәгендә медальләр — кече лейтенантның батырлык билгесе. Икенче группа инвалид булып, күп газаплар белән Галиулла да Яуширмәгә кайтып егыла. Кызга булган көчле мәхәббәт аны яңа терелтә. Алар вәгъдәләренә тугры калып бергә кушылалар. Рәйсә апа Сафина (ире фамилиясе) гаиләсенә шифалы җылылык бирү өчен тырыша. Яшь парлар исән-имин сәламәт балалар табып үстерү хакында хыялланалар. Әмма тормышның башларга да өлгермәгән хатын урын өстенә егыла. Бер-бер артлы хастаханәләрдә яту, эчпошыргыч көннәр — бар да яшь кызга бирелгән сугыш «бүләге». 9 ел урын өстендә ятканнан соң гына II группа инвалидлык бирелә. Көчле дәваланулардан соң аякка баса. Тормыш дәвам итә. Балалар табып үстерәләр. Алар укып Чистайга килеп, гаилә корып яши башлауга.

(Ахыры 4 нче биттә).

***Авыр сугыш елларының ачысын-төчесен барыбыздан да күбрәк татыган,җиңү сәгатен якынайту өчен, тиңдәшсез батырлыклар күрсәткән фидакарь хатын-кызларыбызга дан һәм хөрмәт!***



**300 дән артык ир-егетебез сугыш кырыннан әйләнеп кайта алмый, ятим балалар саны тагы да арта.**




**Әткәй хатлары.**

**Әткәй сүзен әйтеп үсмәдек без.**
**Белмим аннан авыр ни барын.**
**Боекканда җыелып укый идек**
**Әткәбездән килгән хатларны.**
**Суык булса безгә, әни шул ук сандык төбен актарды.**
**Җаннар җылынганчы укыдык без**
**Әткәбездән килгән хатларны.**
**Озата барды гомер буе**
**Әткәбезнең фронт хатлары.**
**Алар безне түбән төшүләрдән,**
**Хурлык эчүләрдән саклады.**




*Иске бишмәтләргә мең кат
рәхмәт,
Качып буламыни чынлыктан:
Көлтә ышыгында төн кунганда,
Без кырауда калып чыныккан.*





# Сугыш чоры балалары.







*Туганнан соң без бит бер атна да*
*Жылы өйдә ятып тормаган.*
*Бишек җырын безгә әнкәй түгел,*
*Арыш башаклары җырлаган.*

*Арышларның җыры керт-керт итеп*
*Урак тешләрендә киселгән.*
*Без бәләкәй идек,ә әнкәйләр аны*
*Ничек чыгаралсын исеннән!*









***Тургайлар да безне юатканнар,***
***Сыйпап-сыйпап җилләр искәннәр.***
***Үлгәнебез шунда үлеп калган,***
***Ә исәннәр...***
***Менә үскәннәр.***





***Тыл ветераннары һәм сугыш чоры балаларын бәйрәм белән тәбрик итү.***










***Беркем дә , бернәрсә дә онытылмый*.**






***Сезгә лаеклы алмаш булып үсәрбез*.**






Их апайлар, абыйлар, сугыш елларында
Теңкәгезгә тиде авырлык.
Заман авырлыгын күтәрергә,
Зур кайгылар баштан үткәрергә,
Кайдан тылсымлы көч таптыгыз да,
Кайдан алдыгыз сез сабырлык?!
Сезнең сабырлыкка, батырлыкка
Мәңге-мәңге хәйран калырлык.



Картаймагыз әле, ветераннар,
Картаймагыз , әй сез тынмас җаннар.
Сезгә тиеш әле бик күп назлар,
Сезгә тиеш әле бик күп язлар.
Буыннардан буыннарга
Күчә барыр сезнең даннар.









# “Әфганстан- йөрәк ярасы.”





*Ык суыдай ашкын гомер ага,*
*Күпме эзләр кала җуелып.*
*Калсын иде без яшәгән дәвер,*
*Тарих битләренә уелып...*

*Дуслык, татулык*



*Голландиедән килгән кунаклар белән*



*Әй аулак өй, аулак өй...*



*Яшәсәк тә төрле илләрдә..*

*Хөрмәтле сугыш чоры*

*балалары!*

*Ходай биргән гомерегездә балаларыгызның, онык-оныкчыкларыгызның олы ихтирамын, игелеген күреп яшәгез! Илебез күге аяз булсын!*

*Беркайчан да күрмик сугышны.*

